КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 31 август г.Казань № 1058

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 317 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 317 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 29 декабрь, 660 нчы; 2006 ел, 19 июнь, 312 нче; 2010 ел, 31 май, 419 нчы; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 26 октябрь, 890 нчы; 2011 ел, 23 декабрь, 1060 нчы; 2012 ел, 10 октябрь, 846 нчы; 2013 ел, 19 март, 185 нче; 2013 ел, 4 декабрь, 955 нче; 2013 ел, 11 декабрь, 974 нче; 2014 ел, 4 июнь, 376 нчы; 2016 ел, 19 март, 150 нче; 2016 ел, 29 октябрь, 796 нчы; 2017 ел, 3 февраль, 58 нче; 2017 ел, 20 апрель, 232 нче; 2017 ел, 18 декабрь, 1008 нче; 2018 ел, 22 март, 161 нче; 2018 ел, 5 июнь, 430 нчы; 2018 ел, 17 декабрь, 1155 нче; 2019 ел, 16 март, 185 нче; 2019 ел, 22 июль, 613 нче; 2020 ел, 11 февраль, 99 нчы; 2020 ел, 11 июль, 575 нче; 2020 ел, 19 август, 710 нчы; 2021 ел, 21 гыйнвар, 19 нчы; 2021 ел, 18 июнь, 476 нчы; 2021 ел, 6 декабрь, 1168 нче; 2022 ел, 22 апрель, 389 нчы; 2022 ел, 1 июнь, 511 нче; 2022 ел, 18 август, 852 нче; 2022 ел, 2 сентябрь, 946 нчы; 2022 ел, 1 ноябрь, 1165 нче; 2022 ел, 5 декабрь, 1288 нче; 2022 ел, 30 декабрь, 1485 нче, 2023 ел, 12 апрель, 451 нче, 2023 ел, 9 июнь, 704 нче, 2023 ел, 2 август, 936 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«*» астөшермәсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«* Код билгеләнеше Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика башкарма хакимият органнары эшчәнлеген оештыру турында» 2023 ел, 26 июнь, 752 нче карары белән расланган Республика башкарма хакимият органнарының дәүләт идарәсе функцияләре кодификаторы нигезендә.»;

3.3 пунктта:

сиксән икенче һәм сиксән өченче абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу эшчәнлеген гамәлгә ашыруга рөхсәт бирә, мондый рөхсәтнең гамәлдә булуын туктатып тора, аннулировать итә һәм яңарта, җиңел такси заказы хезмәте эшчәнлеген гамәлгә ашыруга хокук бирә, җиңел такси заказы хезмәте эшчәнлеген туктатып тора, гамәлдән чыгара һәм мондый хокукның гамәлдә булуын җиңел такси заказы хезмәте эшчәнлеген гамәлгә ашыруга яңарта, шулай ук «Россия Федерациясендә җиңел таксиларда пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану хакында» 2022 елның 29 декабрендәге 580-ФЗ номерлы Федераль законның 4 статьясындагы 1 өлешендә каралган гаризалар һәм мөрәҗәгатьләр, әлеге гаризаларга карата карарлар кабул итү һәм җиңел такси заказы хезмәтләренең төбәк реестрыннан өземтәләр кабул итү турында хәбәрнамәләр формаларын раслый;

җиңел такси белән йөртүчеләрнең төбәк реестрын, җиңел таксиларның төбәк реестрын һәм җиңел такси заказы хезмәтләренең төбәк реестрын алып бара;»;

йөз өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясендә җиңел таксиларда пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану хакында» 2022 елның 29 декабрендәге 580-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясындагы 2 өлешендә каралган «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә җиңел такси белән йөртүче тарафыннан җиңел такси белән йөртүгә тарифлар турында белешмәләр урнаштыру өчен сайтны билгели;».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин